Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең
Әлбәдән торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

8 ноябрь, 2025 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең Әлбәдән торак пункты гражданнарының 2025 елның 8 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 46 (кырык алты).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 26 (егерме алты).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 24 (егерме дүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 2 (ике).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2026 елда Әлбәдән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Күн авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Күн авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Баһауов